РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА АЛЬМЕТЬЕВСКА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» август 2020 ел. г. Альметьевск № 95

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәре муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләренең (директорларының), аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының хезмәте өчен түләү һәм премияләү күләмнәре турында нигезләмәләрне раслау хакында» 2016 елның 15 сентябрендәге 44 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләренең (директорларының), аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының хезмәт хакын түләүне тәртипкә салу максатларында, төгәлләштерү тәртибендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләренең (директорларының), аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының хезмәте өчен түләү һәм премияләү күләмнәре турында нигезләмәләрне раслау хакында» 2016 елның 15 сентябрендәге 44 номерлы карарына (Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 20 декабрендәге 59 номерлы, 2017 елның 3 июлендәге 40 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтага:

1 бүлекнең 1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Предприятие җитәкчесенең хезмәт хакы вазыйфаи окладны һәм компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрне үз эченә ала. Стимуллаштыручы характердагы түләүләр стимуллаштыручы характердагы өстәмәләрне һәм премияләрне үз эченә ала.»;

1 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 1.5 пунктча өстәргә:

«1.5. Предприятие җитәкчесенең хезмәт хакы, әлеге Нигезләмә нигезендә, хезмәт шартнамәсе (хезмәт шартнамәсе буенча өстәмә килешү) нигезендә,

Зак. № 301

зендә, хезмәт шартларын, календарь ае өчен вазыйфаи бурычларны үтәгән өчен окладның беркетелгән күләмен, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр күләмнәрен һәм шартларын, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 2.7 пунктында күрсәтелгән нисбәтнең иң чик дәрәҗәсен күрсәтеп билгеләнә.»;

2 бүлекнең 2.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Җитәкченең вазыйфаи окладь хезмәт шартнамәсе төзегәндә яисә хезмәт шартнамәсен пролонгацияләгәндә районның башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә һәм хезмәт өчен түләү коэффициентына предприятие хезмәткәрләренең исемлектәге составының уртача хезмәт хакын арттыру юлы белән билгеләнә.»;

1 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле 6 бүлек өстәргә:

«6. Җитәкченең вазыйфаи окладьы күләмнәрен һәм аңа өстәмәләрне үзгәртү тәртибе.

6.1. Җитәкче вазыйфаи окладының күләме, вазыйфаи окладны исәпләү гамәлгә ашырыла торган күрсәткечләрне үзгәртү шарты белән (МУП җитәкчесенең тиешле ел өчен хисабы мәгълүматлары буенча) вазыйфаи окладны билгеләү елыннан соң килә торган чираттагы финанс елы нәтиҗәләре буенча яңадан карала.

6.2. Муниципаль унитар предприятиенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләрен исәпкә алып, Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге тәкъдимнәре нигезендә вазыйфаи окладка өстәмәләр күләме үзгәртелә. Җитәкченең вазыйфаи окладына өстәмәләрне үзгәртү турында соңгы карарны Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты кабул итә.

6.3. Җитәкченең вазыйфаи окладь күләмнәрен һәм аңа өстәмәләрне үзгәртү, вазыйфаи окладны һәм/яисә аңа өстәмә түләүләрне үзгәртү турында карар кабул итү датасына гамәлдәге хезмәт шартнамәсенең гамәлдә булу срогы чыккан очракта, җитәкче белән хезмәт килешүенә өстәмә килешү төзү яисә яңа хезмәт шартнамәсе төзү юлы белән гамәлгә ашырыла.».

2 нче кушымтага:

1 бүлекнең 1.3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Җитәкчегә, аның урынбасарларына һәм баш бухгалтерга премияләр бирү предприятие акчасы хисабына башкарыла.»;

түбәндәге эчтәлекле 2.4.1 пунктын өстәргә:

«2.4.1 табышы булмаган аерым тармаклар предприятиеләре җитәкчеләре, объектив сәбәпләр буенча, аларның продукциясенә (эшенә, хезмәт күрсәтүләренә) бәяләрне (тарифларны) үзәкләштерелгән җайга салу белән, мондый продукцияне (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) сатудан кергән керем өлеше предприятиенең гомуми суммасында 50% тан артык тәшкил иткән очракта, әлеге нигезләмә нигезендә премияләр алырга мөмкин.»;

2 бүлекнең 2.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Премияләр күләмнәре турындагы мәсьәләне караганда, район башкарма комитеты муниципаль унитар предприятиеләрнең җитәкчеләренең (директорларның), аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының хезмәт хакы күләмнәрен билгеләү турындагы нигезләмәнең 2.7 пунктындагы нормаларга таянып эш итәргә тиеш. Премияләрнең еллык гомуми суммасы җитәкченең вазыйфаи окладының 300 процентыннан артмаска тиеш.»;

4 бүлектә түбәндәге эчтәлекле 4.2, 4.3 пунктлар өстәргә:

«4.2. Муниципаль унитар предприятие җитәкчесен премиядән тулысынча яисә өлешчә мәхрүм итү турындагы карар башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан кабул ителә һәм, сәбәпләрне мәҗбүри рәвештә муниципаль предприятие җитәкчесенә җиткереп, башкарма комитет күрсәтмәсе белән

рәсмиләштерелә.;

4.3. Премияне тулысынча яки өлешчә мәхрүм итү хокук бозган исәп-хисап чоры өчен башкарыла.».

2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н.Подоваловка йөкләргә.

Шәһәр
Башкарма комитеты җитәкчесе Л.Ф. Вәлиев

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА АЛЬМЕТЬЕВСКА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ